ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

2022 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты доклады хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладын игътибарга алырга.

2. Квалификацияле кадрларны җәлеп итү һәм аларны тармакта калдыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында мәгариф, сәламәтлек саклау, мәдәният системасы хезмәткәрләрен торак белән тәэмин итү программасын әзерләү мөмкинлеген карауны тәкъдим итәргә.

3. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

3.1. «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү», «2023 – 2030 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү», «2015 – 2025 елларга Татарстан Республикасында талантлар белән стратегик идарә итү», «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программаларын, «Мәгариф», «Демография», «Фән һәм университетлар», «Цифрлы икътисад» илкүләм проектларын гамәлгә ашыруны дәвам итүне.

3.2. «Инженер республика», «Яндекс академиясе лицее», «Үсеш ноктасы», «Игелек мәктәбе» региональ проектларын гамәлгә ашыруны методик яктан тәэмин итүне.

3.3. Мәгариф системасын кадрлар белән тәэмин итү, яшь белгечләрне һөнәрдә калдыру, идарәче кадрлар резервын булдыру, остазлык институтын үстерү, педагогларга һәм остазларга ярдәм итү һәм аларның статусын арттыру механизмнарын камилләштерү эшен дәвам итүне.

3.4. Төп предприятиеләр ихтыяҗларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы икътисады тармаклары өчен кадрлар әзерләүче ресурс үзәкләре челтәре булдыру эшен дәвам итүне.

3.5. Югары белем бирү мәгариф оешмалары белән берлектә түбәндәгеләрне дәвам итүне:

– талантлы яшьләрне республикада калдыру өчен шартлар тудыру эшен;

– полилингваль һәм билингваль белем бирү системасы өчен педагогик кадрлар әзерләү һәм аларны яңадан әзерләү системасын үстерүне.

3.6. «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча республика агентлыгы белән берлектә Педагог һәм остаз елы вакыйгаларын төрле яклап яктыртуны дәвам итүне, шулай ук җәмгыятьтә педагог һөнәрләрен популярлаштыруга һәм аларның абруен арттыруга, иң яхшы педагогларның, методистларның һәм остазларның уңай тәҗрибәсен таратуга, җәмәгатьчелекнең игътибарын ата-аналарның һәм педагогларның үзара эшчәнлегендәге актуаль мәсьәләләргә җәлеп итүгә, илдәге педагогик мирасны популярлаштыруга ярдәм итүне.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына, югары белем бирү мәгариф оешмалары җитәкчеләренә 2022 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладында булган тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру чараларын күрүне тәкъдим итәргә (кушымта итеп бирелә).

5. Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетына мәгариф өлкәсендә законнарны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту эшен дәвам итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 14 сентябре
№ 2150-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советының
2023 елның 14 сентябрендәге
2150-VI ДС номерлы карарына
кушымта

**2022 елда Татарстан Республикасында мәгарифне үстерү программаларын гамәлгә ашыру барышы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты докладындагы тәкъдимнәр**

| № т/б | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү сыйфатын арттыру буенча тәкъдимнәре | Тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|
| 1. | 2015 – 2030 елларга Татарстан Республикасында милли мәгариф системасын үстерү концепциясен гамәлгә ашыруны дәвам итәргә | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 2. | Муниципалитетларның милли һәм территориаль үзенчәлекләрен исәпкә алып, туган телдә белем бирүче гомуми белем бирү оешмалары эшчәнлегенә методик ярдәм күрсәтүне гамәлгә ашырырга | |
| 3. | Белем бирү сыйфатын бәяләүнең төбәк системасын камилләштерүне, шул исәптән халыкара чагыштырма тикшеренүләр технологияләрен исәпкә алып, дәвам итәргә | |
| 4. | Педагогик хезмәткәрләрне электрон рәвештә аттестацияләүнең автоматлаштырылган системасын штат режимында кулланырга | |
| 5. | «Татарстан Республикасының фәнни-технологик үсеше» дәүләт программасын гамәлгә ашыру буенча проект офисы эшен оештырырга | Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе |
| | *Педагогларны әзерләү, яңадан әзерләү, аларның квалификациясен күтәрү һәм аларга өстәмә һөнәри белем бирү* | |
| 6. | Кадрлар потенциалын камилләштерү, индивидуаль үсеш траекторияләрен төзү максатында педагогик хезмәткәрләрнең һөнәри кыенлыкларын диагностикалау системасын булдыру эшен, шул исәптән өстәмә һөнәри белем бирүнең яңа рәвешләрен һәм модельләрен эшләүне, дәвам итәргә | «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, өстәмә һөнәри белем бирү оешмалары белән берлектә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 7. | Педагогик хезмәткәрләрне һәм идарәче кадрларны фәнни-методик тәэмин итүнең бердәм системасын булдырырга һәм үстерергә мөмкинлек бирә торган өзлексез педагогик белем бирүне үстерү эшен дәвам итәргә | |

| № т/б | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү сыйфатын арттыру буенча тәкъдимнәре | Тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|
| 8. | Барлык бәяләү процедураларын исәпкә алып, өстәмә һөнәри белем бирү программаларының адреслылыгын арттыру юлы белән педагогларның предмет, методик, психологик-педагогик, коммуникатив компетенцияләрен камилләштерү эшен дәвам итәргә | |
| 9. | Педагогларга яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартларын гамәлгә ашыруга, федераль төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә кертүгә һәм укучыларның функциональ грамоталылыгын үстерүгә бәйле мәсьәләләрдә методик ярдәмне көчәйтергә | |
| 10. | «Татарстан Республикасында электрон белем бирү» дәүләт мәгълүмат системасында диагностиканы апробацияләү нәтиҗәләрен исәпкә алып, бәяләү чараларын камилләштерергә | |
| 11. | Ачыкланган һөнәри кыенлыкларны, шул исәптән функциональ грамоталылыкны исәпкә алып, индивидуаль белем бирү маршрутларын эшләүне һәм гамәлгә кертүне дәвам итәргә | |
| 12. | Һөнәри компетенцияләр кытлыгын билгеләүне, стажировкаларның тармак системасын, алдынгы цифрлы технологияләр белән укытуны, киң тәҗрибә алмашу һәм ирекле иҗади үсеш мөмкинлекләрен үз эченә алган укытучы үсешен тәэмин итүнең мотивацияле методикаларын булдырырга | |
| 13. | Педагогик хезмәткәрләрнең ата-аналар белән үзара эшчәнлеген оештыру, тәрбияләү программаларын гамәлгә ашыру буенча, иң яхшы тәҗрибәләрне исәпкә алып, методик тәкъдимнәр эшләргә | |
| 14. | Белем бирү барышында катнашучыларга психологик ярдәм күрсәтү мәсьәләләре буенча укытучылар, сыйныф җитәкчеләре өчен кыска вакытлы укыту программалары булдырырга | |
| 15. | Республикада муниципаль методик хезмәтнең ярдәм системасын үстерүне дәвам итәргә | |
| 16. | Педагогик белем бирү юнәлешләре буенча югары уку йортларына | |

| № т/б | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү сыйфатын арттыру буенча тәкъдимнәре | Тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|
| | максатчан кабул итү механизмнарын камилләштерү һәм яшь укытучыларны сайлаган һөнәрендә калдыруга шартлар тудыру буенча эшне дәвам итәргә | |
| 17. | Булачак абитуриентларның һөнәри пробаларны гамәлгә ашыру, үз-үзләрен күрсәтү һәм аларны педагог һөнәренә җәлеп итү өчен, киңлек буларак, психологик-педагогик юнәлештәге профильле сыйныфлар челтәрен үстерергә | |
| 18. | Идарәче кадрлар резервын булдыру системасын камилләштерү эшен активлаштырырга | |
| 19. | Стажировкалар, мастер-класслар, авторлык программалары һәм башкалар рәвешендә мәгариф оешмалары һәм идарәче командалар җитәкчеләрен һөнәри үстерү эшен дәвам итәргә | |
| | *Татарстан Республикасы муниципаль районнарында һәм шәһәр округларында белем бирү системасы* | |
| 20. | Тиешле мәктәпкәчә һәм гомуми белем бирү оешмаларында тулаем тел мохитен булдыру һәм үстерү, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә яшәүче халыкларның туган телләрен, мәдәниятләрен һәм гореф-гадәтләрен өйрәнүгә ярдәм итү эшен оештырырга | Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыклары |
| 21. | Олимпиадалар, башка интеллектуаль һәм (яисә) иҗади конкурслар, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрне, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнүгә сәләтләрне, фәнни (фәнни-тикшеренү), иҗади эшчәнлеккә, физкультура-спорт эшчәнлегенә кызыксынуны үстерүгә, шулай ук фәнни белемнәрне, иҗат һәм спорт казанышларын пропагандалауга юнәлдерелгән чаралар үткәрү аша сәләтле балаларны ачыклау өчен шартлар тудыру эшен дәвам итәргә | |
| 22. | Яшь педагогларны муниципалитетның мәгариф оешмаларына җәлеп итү һәм аларда калдыру буенча чаралар комплексын эшләргә һәм гамәлгә ашырырга | |

| № т/б | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү сыйфатын арттыру буенча тәкъдимнәре | Тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|
| 23. | Татарстан Республикасы мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүнең персональләштерелгән системасы турындагы нигезләмә нигезендә мәгариф хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүне һәм аларны яңадан әзерләүне оештыруны тәэмин итәргә | |
| 24. | Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларында, шул исәптән сәламәтлек ягыннан мөмкинлекләре чикле балалар өчен, мәктәпкәчә белем бирүнең федераль дәүләт белем бирү стандартларына туры килә торган шартлар булдыру эшен дәвам итәргә | |
| 25. | Балаларга өстәмә белем бирү системасында балаларга өстәмә белем бирүне финанслау системасын камилләштерүгә юнәлдерелгән, балаларга өстәмә белем бирүнең сыйфатын яхшыртуны, балаларга өстәмә белем бирү системасында конкурентлык мохите тудыруны, шулай ук балаларга өстәмә гомуми белем бирү программалары буенча укуга тигез мөмкинлек булдыруны тәэмин итә торган оештыру-финанс механизмнарын булдыру эшен дәвам итәргә | |
| 26. | Ата-аналарның иҗтимагый берләшмәләрен үстерергә, ата-аналарны мәгариф оешмасы белән идарә итүдә катнашуга, белем бирү сыйфатын бәяләүгә җәлеп итәргә | |
| 27. | Психологик-педагогик һәм медик-социаль үзәкләрдә, психологик-педагогик хезмәтләрдә хезмәт күрсәтүләрнең сыйфатын, психологик-педагогик һәм медик-социаль үзәкләрдә һәм хезмәтләрдә педагогик кадрларның белем бирү һәм һөнәри дәрәҗәсен арттыруга юнәлдерелгән чаралар комплексын гамәлгә ашыруны дәвам итәргә | |
| 28. | Муниципаль берәмлекләр территориясендә урнашкан «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында грант алучы мәгариф оешмаларына грантларны гамәлгә ашыру кысаларында алынган акчаларны финанс елы ахырына кадәр йөз процент үзләштерүгә ярдәм күрсәтергә | |

| № т/б | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының белем бирү сыйфатын арттыру буенча тәкъдимнәре | Тәкъдимнәрне гамәлгә ашыру өчен җаваплылар |
|---|---|---|
| 29. | Белем бирү процессында илкүләм проектлар, федераль программалар һәм проектлар чаралары кысаларында сатып алынган җиһаздан, укыту һәм тәрбияләү чараларыннан фактта файдалануга даими мониторинг үткәрергә | |
| | *Татарстан Республикасында югары белем бирүне үстерү* | |
| 30. | Укучыларның этник үзаңын булдыруга, үз халкының, үз өлкәсенең тарихы, теле, мәдәнияте, Россия халыклары мәдәни мирасы һәм кешелек тарихы нигезләре турында белемнәр алуга юнәлдерелгән тәрбия эшен оештырырга | Татарстан Республикасында югары белем бирү мәгариф оешмалары җитәкчеләре |
| 31. | Талантлы яшьләрне республикада калдыру өчен шартлар тудыру, Россия Федерациясе субъектларыннан абитуриентларны җәлеп итү эшен дәвам итәргә | |
| 32. | Республикада югары белем бирүне инновацион үстерүгә юнәлдерелгән федераль конкурсларда, грант программаларында, проектларда актив катнашуны дәвам итәргә | |
| 33. | Чит ил студентларының тел ягыннан һәм социаль яктан яраклашу, аларның республиканың мәгариф һәм мәдәни тормышына кушылу эшен дәвам итәргә | |
| 34. | «Технологик эшкуарлык университет платформасы» федераль проекты кысаларында «Студентлар стартабы»на 3 нче һәм 4 нче чират сайлап алуларга грант алучыларның проектларына ярдәм итүне тәэмин итәргә | |